РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«16» декабря 2019 г. г. Альметьевск № 182

Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, хокукый мониторинг тәртибендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтаның «Шәһәр Башкарма комитеты вәкаләтләре» 2 бүлегендә:

1.1.1. 2 пунктның 4 пунктчасы дүртенче абзацында «торак урыннар» сүзләрен «күпфатирлы йорттагы торак» сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2. 2 пунктның 10 подпункчасы уналтынчы абзацта «күзәтүчесез хайваннарны аулау һәм асрау чараларын» сүзләрен «хуҗаларсыз тереклек итүче хайваннар белән эш итү эшчәнлеген» сүзләренә алмаштырырга.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә (Бочкарев Н.А.) йөкләргә.

«АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ»

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Зак. № 3223